**КАРАР**

**30 ноябрь, 2024 ел** **№2**

**Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге Каенсар авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены ннәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 30 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Каенсар авыл җирлеге Каенсар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яки аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су суырту манараларын һәм су саклау зоналарын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, су суырту манарасын буяу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;)

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Каенсар авылында юлларны карап тоту, тракторны карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм комплектлау әйберләренең запас частьләре, тагылма җайланмалар сатып алу, тракторчы хезмәтләре күрсәтү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Мәктәп, Г. Тукай урамнарына, вак таш салып, юллар төзү һәм чокырларны ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; махсус техника хезмәтләре Каенсар авылында 1 Май урамындагы күпергә култыксалар урнаштыру, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Каенсар авыл җирлегенә элмә такталар сатып алу һәм урнаштыру, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; массакүләм ял итү урыннарын, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннарын һәм янәшәдәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, массакүләм ял итү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.)

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар тоту, төзекләндерү, (территорияне төзекләндерү һәм карап тоту, зират өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып

алу, гербицидлар сатып алу, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;)

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **264** кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **150** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **150** кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **0** кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Каенсар авыл җирлеге Каенсар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яки аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су суырту манараларын һәм су саклау зоналарын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, су суырту манарасын буяу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;)

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Каенсар авылында юлларны карап тоту, тракторны карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм комплектлау әйберләренең запас частьләре, тагылма җайланмалар сатып алу, тракторчы хезмәтләре күрсәтү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Мәктәп, Г. Тукай урамнарына, вак таш салып, юллар төзү һәм чокырларны ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; махсус техника хезмәтләре Каенсар авылында 1 Май урамындагы күпергә култыксалар урнаштыру, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Каенсар авыл җирлегенә элмә такталар сатып алу һәм урнаштыру, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник

күзәтчелекне гамәлгә ашыру; массакүләм ял итү урыннарын, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннарын һәм янәшәдәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, массакүләм ял итү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.)

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар тоту, төзекләндерү, (территорияне төзекләндерү һәм карап тоту, зират өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу, гербицидлар сатып алу, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;)

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Каенсар авыл җирлеге башлыгы И.Х. Исхаков